Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның 28 августындагы 233 номерлы карары «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче укучыларны туклану белән тәэмин итүне оештыру турында»

Татарстан Республикасының 2004 елның 8 декабрендәге 63-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында»гы Канунына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 22 сентябрендәге 726 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларны бушлай кайнар туклану белән оештыру һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнарны һәм 2026 елга һәм 2027-2028 еллар план чорына башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча бер укучыга кайнар туклануның уртача бәясен раслау турында»гы карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 3 октябрендәге 787 номерлы «Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларны туклану белән тәэмин итү бәясе нормативларын 2026 елга һәм 2027-2028 еллар план чорына раслау турында»гы карарына туры китереп, шулай ук балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген ныгыту, кайнар туклану белән тәэмин итү, гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алучыларның сәламәтлеген саклау максатларында Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р к ы л а :

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында белем алучылар өчен кайнар туклану оештырырга.

1.1. Билгеләргә:

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы шәһәр һәм авыл гомуми белем бирү учреждениеләренең 1-4 сыйныф укучылары өчен бер укучыга көненә балансланштырылган кайнар туклану бәясе – 77,76 сум;

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы шәһәр һәм авыл гомуми белем бирү учреждениеләренең 5-11 сыйныф укучылары өчен бер укучыга көненә балансланштырылган кайнар туклану бәясе – 122,76 сум;

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы шәһәр һәм авыл гомуми белем бирү учреждениеләрендә озайтылган көн төркеменә йөрүче укучылар өчен бер укучыга көненә өстәмә туклану бәясе – 45 сум.

2. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче укучылар өчен туклануны 77,76 сум күләмендә оештырырга, ул бер уку елына укучыларны бушлай туклану белән тәэмин итүгә каралган 77,76 сум күләмендәге субсидиядән гыйбарәт.

3. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алучылар өчен көн саен 77,76 сумлык кайнар туклану оештырырга. Ул Татарстан Республикасы бюджетыннан бер уку көненә бушлай туклануны оештыруга каралган 10,7 сум күләмендәге субсидиядән һәм көненә 67,06 сумлык ата-аналар түләвеннән гыйбарәт.

4. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алучылар өчен, ата-ана (канунлы вәкил) гаризасы нигезендә, көненә 45 сумлык ата-аналар түләве исәбенә өстәмә (икенче) кайнар туклану оештырырга.

5. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының шәһәр һәм авыл гомуми белем бирү учреждениеләрендә озайтылган көн төркемендә йөрүче белем алучылар өчен, ата-аналар түләве исәбенә, бер укучыга көненә 45 сумлык өстәмә кайнар туклану оештырырга.

6. Социаль якланмаган гаиләләрдәге балаларга адреслы социаль ярдәм күрсәтү максатларында ата-ана түләвеннән азат итәргә

- Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә 5-11 сыйныф укучыларының ике тапкыр кайнар туклануы өчен;

- шәһәр һәм авыл гомуми белем бирү учреждениеләрендә озайтылган көн төркемендә йөрүче белем алучыларның өстәмә кайнар туклануы өчен.

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы бюджетыннан расланган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә туклануны оештыру өчен түбәндәге категорияләр:

- сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикле (СМЧ) балалар;
- махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның балалары;
- Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының 15.07.2026 елгы №182 «Махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затларга һәм башка категория затларга ярдәм чараларын билгеләү турында»гы карарының 1 нче пунктының җиденче абзацында күрсәтелгән затлар.

7. Әлеге карарның 6 нчы пунктында күрсәтелгән төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү укучыларының кайнар туклануы Татарстан Республикасы бюджетыннан бер уку көненә бушлай туклануны оештыру өчен каралган 10,7 сум күләмендәге субсидия һәм Апас муниципаль районы бюджетыннан һәр уку көненә бер укучыга 112,06 сум исәбеннән оештырыла.

8. Апас муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә 5-11 сыйныф укучыларына Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы бюджетыннан расланган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә, җирле бюджет хисабына көненә 77,76 сум исәбеннән, түбәндәге категорияләргә ташламалы кайнар туклану оештырырга:

• инвалид балалар;

• социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрдән балалар;

• күп балалы гаиләләрдән балалар;

• тәрбиягә алынган гаиләләрдә тәрбияләнүче балалар;

• ятим балалар һәм опекада булган балалар;

• Россия Федерациясе эчке эшләр органнары хезмәткәрләренең балалары;

• хәрби хәрәкәтләрдә катнашу нәтиҗәсендә I, II яки III төркем инвалидлык алган хәрби хәрәкәтләр ветераннарының балалары;

• Россия Федерациясе Дәүләт хезмәтләре порталындагы гариза бирүченең шәхси кабинеты аша алынган белешмә белән расланган аз керемле гаиләләрдән балалар;

• гаиләнең бер әгъзасына туры килгән уртача айлык кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбән булган аз керемле гаиләләрдән балалар (акт буенча);

• әти-әниләренең берсе инвалид булган гаиләләрдән балалар.

9. Сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән, инвалид балалар булган 1-11 сыйныф укучылары өчен, аларның укуы өйдә оештырылган очракта, бушлай ике тапкыр туклануны акчалата компенсация белән алмаштыру

мөмкинлеген булдырырга (бушлай ике тапкыр туклануны акчалата компенсация белән алмаштыру турында гариза нигезендә).

10. Социаль ярдәм күрсәтү турындагы мәгълүмат Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә, шулай ук ЕЦП операторы билгеләгән форматларга туры китереп, Социаль өлкәдәге Бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформада (алга таба – ЕЦП) урнаштырыла.

11. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләре директорларына:

- өстәмә социаль ярдәм чараларына мохтаҗ укучыларны кайнар туклану белән тәэмин итүне оештыру буенча комиссия төзергә, аның составы учреждение директоры тарафыннан раслана;

- гомуми белем бирү учреждениеләренең ашханәләрендә туклануны оештыруга контрольлекне «Балаларны һәм яшьләрне тәрбияләү һәм укыту, ял итү һәм сәламәтләндерү оешмаларына карата санитар-эпидемиологик таләпләр» СП 2.4.3648-20 санитар кагыйдәләре һәм «Халыкны җәмәгать туклануы белән тәэмин итүне оештыруга карата санитар-эпидемиологик таләпләр» СанПиН 2.3/2.4.3590-20 санитар-эпидемиологик кагыйдәләре һәм нормалары нигезендә гамәлгә ашырырга.

12. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесенә:

- төп туклыклы матдәләр белән балансланган, витаминнар һәм микронутриентлар белән баетылган иртәнге һәм (яки) төшке ашларның нормаларын һәм сыйфатын исәпкә алуны һәм контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

- укучыларны кайнар туклану белән тәэмин итүгә бүлеп бирелгән акчаларның максатчан файдаланылуын һәм исәпкә алынуын контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

- гомуми белем бирү учреждениеләренә азык-төлекнең өзлексез килеп торуын координацияләүне һәм контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

- социаль ярдәм күрсәтү турындагы мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә, шулай ук ЕЦП операторы билгеләгән форматларга туры китереп, Социаль өлкәдәге Бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформада (алга таба – ЕЦП) урнаштырырга.

13. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына Апас муниципаль районы бюджетында каралган ассигнованиеләр чикләрендә белем бирү учреждениеләренең барлык укучылары өчен уку вакытында кайнар туклануны оештыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны гамәлгә ашырырга.

14. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләрендә өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ булган укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру тәртибе турындагы нигезләмәне расларга.

15. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 11 декабрендәге 293 номерлы «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче укучыларны тукландыруны оештыру турында»гы карары;

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 18 декабрендәге 296 номерлы ««Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче

укучыларны тукландыруны оештыру турында»гы карарга үзгәрешләр кертү хакында»гы карары;

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 7 маендагы 83 номерлы ««Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче укучыларны тукландыруны оештыру турында»гы карарга үзгәрешләр кертү хакында»гы карары;

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 28 маендагы 103 номерлы ««Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче укучыларны тукландыруны оештыру турында»гы карарга үзгәрешләр кертү хакында»гы карары;

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 26 сентябрендәге 195 номерлы ««Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче укучыларны тукландыруны оештыру турында»гы карарга үзгәрешләр кертү хакында»гы карары.

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 3 декабрендәге 248 номерлы «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче укучыларны туклану белән тәэмин итүне оештыру турында»гы карарга үзгәрешләр кертү хакында» карары;

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның 25 февралендәге 45 номерлы «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче укучыларны туклану белән тәэмин итүне оештыру турында»гы карарга үзгәрешләр кертү хакында» карары.

16. Әлеге карар 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

17. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында (https://apastovo.tatarstan.ru/) урнаштырырга һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга.

18. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Ввб җитәкче Р.З. Замдиханов

Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районы
Башкарма комитеты
2026 елның 28 августындагы 233 номерлы
карары белән расланды

Апас муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләрендә өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру тәртибе турындагы Нигезләмә

1. «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләрендә өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучыларны кайнар туклану белән тәэмин итү тәртибе турында»гы әлеге Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) гомуми белем бирү учреждениеләрендә социаль яклanмаган гаиләләрдән булган балаларны кайнар туклану белән тәэмин итү максатыннан, укучыларның түбәндәге категорияләре өчен эшләнде:

- социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрдән булган балалар;
- күп балалы гаиләләрдән булган балалар;
- инвалид балалар;
- сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикле булган (СМЧ) балалар;
- тәрбиягә алынган гаиләдә тәрбияләнүче балалар;
- ятим балалар һәм опекада булган балалар;
- Россия Федерациясе эчке эшләр органнары хезмәткәрләренең балалары;
- махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның балалары;
- Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның 15 июлендәге 182 номерлы «Махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затларга һәм башка категория затларга ярдәм чараларын билгеләү турында»гы карарының 1 нче пунктының җиденче абзацында күрсәтелгән затлар;
- хәрби хәрәкәтләрдә катнашу нәтиҗәсендә I, II яки III төркем инвалидлык алган хәрби хәрәкәтләр ветераннарының балалары;
- Россия Федерациясе Дәүләт хезмәтләре порталындагы гариза бирүченең шәхси кабинеты аша алынган белешмә белән расланган аз керемле гаиләләрдән булган балалар;
- гаиләнең бер әгъзасына туры килгән уртача айлык кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбән булган аз керемле гаиләләрдән булган балалар (акт буенча);
- әти-әниләренең берсе инвалид булган гаиләләрдән булган балалар.

2. Социаль яктан якланмаган гаиләләрдәге балаларга адреслы социаль ярдәм түбәндәге юллар белән гамәлгә ашырыла:

1) освобождения от родительской платы

- Апас муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә 5-11 сыйныф укучылары өчен ике тапкыр кайнар туклану өчен,

- шәһәр һәм авыл гомуми белем бирү учреждениеләрендә озайтылган көн төркемендә йөрүче укучылар өчен өстәмә кайнар туклану өчен,

в пределах утвержденных бюджетных ассигнований из бюджета Апастовского муниципального района на организацию питания следующие

категории:

- сәламәтлек мөмкинлекләре чикле (СМЧ) балалар;
- махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның балалары;

Апас муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның 15 июлендәге 182 номерлы «Махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затларга һәм башка категория затларга ярдәм чараларын билгеләү турында»гы карарының 1 нче пунктының җиденче абзацында күрсәтелгән затлар;

2) түбәндәге категорияләргә Апас муниципаль районы бюджетыннан расланган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә, Апас муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә 5-11 сыйныф укучылары өчен көненә 77,76 сум исәбеннән җирле бюджет хисабына ташламалы кайнар туклануны оештыру юлы белән:

• инвалид балалар;

• социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрдән булган балалар;

• күп балалы гаиләләрдән булган балалар;

• тәрбиягә алынган гаиләдә тәрбияләнүче балалар;

• ятим балалар һәм опека астындагы балалар;

• Россия Федерациясе эчке эшләр органнары хезмәткәрләренең балалары;

• хәрби хәрәкәтләрдә катнашу нәтиҗәсендә I, II яки III төркем инвалидлык алган хәрби хәрәкәтләр ветераннарының балалары;

• Россия Федерациясе Дәүләт хезмәтләре порталында гариза бирүченең шәхси кабинеты аша алынган белешмә белән расланган аз керемле гаиләләрдән булган балалар;

• гаиләнең бер әгъзасына туры килгән уртача айлык кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбән булган аз керемле гаиләләрдән булган балалар (акт буенча);

• әти-әнисенең берсе инвалид булган гаиләләрдән булган балалар.

3. Әлеге Нигезләмәнең 2 нче пунктының 1 нче пунктчасында күрсәтелгән укучыларны бушлай туклану белән тәэмин итү, 2 нче пунктчасында күрсәтелгән укучыларны ташламалы туклану белән тәэмин итүне оештыру өчен гомуми белем бирү оешмасында комиссия төзелә. Аның составына директор яки директор урынбасары, укучыларны тукландыруны оештыру өчен җаваплы зат, ата-аналар комитеты вәкиле, гомуми белем бирү оешмасының педагогик һәм административ составыннан башка затлар кертелә. Комиссия әгъзаларының гомуми саны биш кешедән ким булмаска тиеш.

Комиссия кирәк булганда:

- утырыш үткәрә;
- тәкъдим ителгән документларны карый һәм бушлай яки ташламалы туклану бирү мөмкинлеге турында карар кабул итә;
- әлеге Нигезләмәнең 2 нче пунктында күрсәтелгән укучылар исемлеген елга ике тапкыр: агымдагы елның 10 гыйнварына һәм 1 сентябренә формалаштыра;
- утырышка укучыларның ата-аналарын (канунлы вәкилләрен) чакырырга хокуклы;
- гаризаларны карау нәтиҗәләре буенча исемлекләргә үзгәрешләр кертә.

Комиссия утырышы, анда комиссия әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән икесе катнашкан очракта, вәкаләтле дип санала. Комиссия карары утырышта катнашучы әгъзаларның күпчелек тавышы белән кабул ителә.

Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул утырышта катнашкан барлык комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана һәм утырыш үткәрелгән

көннән соң 3 эш көненнән дә соңга калмыйча комиссия рәисе тарафыннан раслана.

4. Укучыларга бушлай яки ташламалы туклану хокукы бирү өчен, аларның әти-әниләре (канунлы вәкилләре) сыйныф җитәкчесенә әлеге Нигезләмәгә кушымтада күрсәтелгән форма буенча кәгазь рәвешендәге гаризаны һәм әлеге Нигезләмәнең 1 нче пунктында күрсәтелгән статусны раслаучы документларны тапшыралар:

социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрдән булган балалар өчен – мәгълүматлар СКХ (социаль куркыныч хәл) базасыннан алына;

күп балалы гаиләләрдән булган балалар өчен – таныклык күчермәсе;

инвалид балалар өчен – раслаучы белешмә;

сәламәтлек мөмкинлекләре чикле (СМЧ) балалар өчен – раслаучы белешмә;

тәрбиягә алынган гаиләләрдә тәрбияләнүче балалар өчен – раслаучы белешмә;

ятим балалар һәм опека астындагы балалар өчен – раслаучы белешмә;

Россия Федерациясе эчке эшләр органнары хезмәткәрләренең балалары өчен – раслаучы белешмә.

4.1. Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның балалары өчен статусны раслаучы белешмә таләп ителми. Әлеге Нигезләмә нигезендә бушлай туклану алу хокукы Россия Оборона министрлыгының мәгълүматлар витринасыннан алынган мәгълүматлар нигезендә раслана.

5. Сыйныф җитәкчеләре:

ата-аналардан (канунлы вәкилләрдән) бушлай яки ташламалы туклану белән тәэмин итү турында гариза кабул итәләр;

гариза алынган көннән өч көн эчендә аны комиссия каравына юллыйлар;

сыйныфтагы укучыларның туклануын категорияләр буенча исәпкә алып баралар;

укучылар һәм аларның ата-аналары (канунлы вәкилләре) арасында тулы кыйммәтле туклануның кирәклеге турында аңлату эшләре алып баралар;

сыйныфның барлык укучыларының ашханәгә йөрүен контрольдә тоталар;

сыйныф укучылары тукланган вакытта ашханәдә булалар.

6. Гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесе:

- әлеге Нигезләмәнең 1 нче пунктында күрсәтелгән укучылар исемлеген елга ике тапкыр: агымдагы елның 10 гыйнварына һәм 1 сентябренә раслый;

әлеге Нигезләмәнең 2 нче пункты нигезендә укучыларны бушлай яки ташламалы туклану белән тәэмин итү турында боерык чыгара;

әлеге Нигезләмәнең 2 нче пунктында күрсәтелгән укучылар исемлеген Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУга тәкъдим итә.

7. Ата-аналар (канунлы вәкилләр) тапшырылган документларның дөреслеге өчен җаваплылык йөртәләр. Ата-аналар (канунлы вәкилләр) тарафыннан гаризада күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, учреждение укучыларга бушлай яки ташламалы туклану бирүдән баш тарта.

8. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ гомуми белем бирү учреждениеләренә барып, укучыларны туклану белән тәэмин итү мәсьәләләрен күзәтә.

9. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләренә кагыла.

*Апас муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләрендә өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучыларны кайнар туклану белән тәэмин итүне оештыру тәртибе турындагы нигезләмәгә кушымта*

Өстәмә социаль ярдәм чараларына мохтаҗ булган укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру комиссиясенә

_______________________________________

(гариза бирүченең Ф.И.О.)

яшәү урыны:

__________________________________

заявление.

Минем улыма (кызыма),

__________________________________________________________________________

*(Ф.И.О. тулысынча)*

______ сыйныфта укучыга, бушлай/ташламалы кайнар туклану бирелүен сорыйм *(кирәген сызарга)*.

Өстәмә мәгълүмат:

__________________________________________________________________________

__________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

Мин, бушлай/ташламалы туклану алуга йогынты ясаучы хәлләр үзгәргән очракта, 5 көн эчендә

*(кирәген сызарга)*

бу хакта мәгариф оешмасын язмача хәбәр итәргә бурычланам.

Минем һәм гаризада күрсәтелгән, шулай ук тапшырылган документлардагы баламның шәхси мәгълүматларын эшкәртергә ризалык бирәм.

Гаризага түбәндәгеләрне беркетеп җибәрәм:

__________________________________________

__________________________________________

"___"_________ 202__ ел /______________________

(Ф.И.О.) (имза)